| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 21 мае** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1362** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 03 декабрендәге 2652 номерлы “Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында” карары үз көчен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 04 мартындагы 483 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан ТР Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт адресы белән чыгу уңаеннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 03 декабрендәге 2652 номерлы «Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында» карары үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:

-күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУна;

- торак биналар милекчеләренә җибәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин